**СОВЕТ ЯМАШУРМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422735, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Ямашурма, ул.Советская, 5

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯМАШИРМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422735, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Ямаширмэ авылы, Совет урамы, 5

Тел./факс 8(84365)777-02, e-mail:Yamash.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**07 сентябрь 2020 ел** **№163**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлеге җирле үзидарә органының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшыру турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.5 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешенә, Ямаширмә авыл җирлеге Советының 2009 елның 8 ноябрендәге 136 номерлы карары (2009 елның 13 декабрендәге 146 номерлы редакциясендә) белән расланган Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибенә, Ямаширмә авыл җирлеге Уставы, Ямаширмә авыл җирлеге Советы, Ямаширмә авыл җирлеге

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Җирләүгә тарифлар билгеләү һәм җирләү эше өлкәсендә җирле үзидарә вәкаләтле органы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өлешендә ритуаль хезмәтләр оештыру буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшырырга;
2. Әлеге карарны карау өчен Биектау муниципаль районы Советына җибәрергә.
3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә (Мухтаров Фәнил Камил улы) Биектау муниципаль районы Советы карары кабул ителгәннән соң 10 календарь көннән дә артмыйча, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турындагы килешү төзү буенча як булырга;
4. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталының рәсми сайтында: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы Ф.К.Мухтаров